**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4323**
**26.05.2023**

Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга субсидияләр бирү өлкәсендә Башкарма комитетның аерым карарлары үз көчен югалтуны тану турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.21, 5.22 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:
1) 2020 елның 22 апрелендә «Челнинские известия» газетасының 30 нчы санында бастырып чыгарылган һәм 2020 елның 22 апрелендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган Башкарма комитетның «Муниципаль-шәхси партнерлык кысаларында спорт объекты төзү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны каплау максатында шәһәр бюджетыннан субсидия бирү турында» 2020 елның 14 апрелендәге 1827 номерлы карары;
2) 2020 елның 14 октябрендә «Челнинские известия» газетасының 76 нчы санында бастырып чыгарылган һәм 2020 елның 16 октябрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган Башкарма комитетның «Башкарма комитетның 2020 елның 14 апрелендәге 1827 номерлы карары белән расланган муниципаль-шәхси партнерлык кысаларында спорт объекты төзү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны каплау максатында шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 12 октябрендәге 5218 номерлы карары;
3) 2022 елның 9 февралендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган Башкарма комитетның «Гражданнарның аерым категорияләре өчен автомобиль

транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында шәһәр бюджетыннан субсидия бирү турында» 2022 елның 3 февралендәге 491 номерлы карары;

4) 2022 елның 23 мартында Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган Башкарма комитетның «Шәһәр элемтәсендәге муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яки) шәхси эшмәкәрләрнең пассажирларда яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация узуны яки соңгы алты ай эчендә әлеге авыруны кичерү фактын раслаучы персональ QR-кодлар, яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация ясауга медицина ягыннан каршылыклар булуны раслаучы гамәлдәге персональ QR-кодлар булуны тикшерүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү буенча чыгымнарын кире кайтару максатында шәһәр бюджетыннан субсидия бирү турында» 2022 елның 16 мартындагы 1359 номерлы карары.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов